Республика Татарстан
Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

ул.Центральная, д. 30, пос.Победа
Азнакаевский район, 423312

Үзәк урамы, 29 нче йорт, Җиңү
бистәсе, Азнакай районы, 423312

Тел. (факс) 8(85592) 42-1-38; e-mail: Vahit.Azn@tatar.ru
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «24» ноябрь 2021г. № 7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Заречье торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Заречье торак пунктында Үзәк урам 20 йорт адресы буенча 2021 елның 5 декабрендә 11 сәгать 00 минутта Заречье торак пункты Үзәк урам 1 йорттан 40 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Заречье торак пунктында 2022 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсрәләне расларга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Заречье торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Заречье торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

- Заречье торак пунктында урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү

(энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча эшләр өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай районы Вахитов
авыл җирлеге башлыгы И.Б. Бохарова